ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

10 08 2020 г. № 528

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 февралендәге 267 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы чикләрендә даими пассажирлар йөртү буенча муниципаль маршрутларны билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, карар бирәм:

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 февралендәге 267 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы чикләрендә даими пассажирлар йөртү буенча муниципаль маршрутларны билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару тәртибен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы чикләрендә даими пассажирлар йөртү буенча муниципаль маршрутларны билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару тәртибендә:

2.12 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3.1 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) исеме, урнашу урыны (юридик зат өчен), фамилиясе, исеме һәм, әгәр булса, атасының исеме, яшәү урыны (шәхси эшмәкәр өчен), салым түләүченең идентификация номеры, почта адресы, элемтә өчен телефоннар;»;

3.2 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) исеме, урнашу урыны (юридик зат өчен), фамилиясе, исеме һәм, әгәр булса, атасының исеме, яшәү урыны (шәхси эшмәкәр өчен), салым түләүченең идентификация номеры, почта адресы, элемтә өчен телефоннар;»;

4.1. пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

5) әлеге маршрутны билгеләү яки үзгәртү турында гаризада күрсәтелгән юридик затның, шәхси эшмәкәрнең яисә гади ширкәтнең бер әгъзасының булса да, административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы нигезендә транспорт һәм юл хәрәкәте өлкәсендә административ хокук бозу кылган өчен билгеләнгән, административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән түләү срогы чыккан түләнмәгән административ штрафы бар.».

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов